**Республика Татарстан**
**Совет Большенуркеевского**
**сельского поселения**
**Сармановского муниципального**
**района**

Ул. Школьная, д. 32, с. Большое Нуркеево
Сармановский район, 423372

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының**
**Зур Нөркәй**
**авыл җирлеге Советы**

Мәктәп урамы, 32 нче йорт, Зур
Нөркәй авылы, Сарман районы, 423372

---

РЕШЕНИЕ
09 июнь 2020 ел

КАРАР
№ 118

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы көрәш турында законнарын камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы « Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 78-80 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 9 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман районы Прокуратурасы протесты нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге
Советы Рәисе Р.М.Гайсин

Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Советының 2020 елның 09 июньдәге 118номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**«Зур Нөркәй авыл җирлеге»**
**Муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1) 7 статьяның 9 пунктыннан «шулай ук җирлекнең торак пунктлары чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарыннан, махсус сакланылучы табигать территорияләрендәге урманнардан файдалануны, аларны саклауны, торгызуны оештыру» сүзләрен төшереп калдырырга.

2) 7 статьяның 10 пунктын «муниципаль район» сүзләреннән соң «Җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары исеме» сүзләрен өстәргә.

3) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:
«20) Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яисә аны капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына туры китерү турында карар кабул итү.».

4) 38 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Авыл җирлеге башлыгы әлеге Уставның 25 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән вазыйфаларда эшли алмый, шулай ук хокуклы түгел:
1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;
2), түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:
а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;
б) коммерцияле булмаган оешма идарәсендә түләүсез нигездә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, Җирлек сайлау комиссиясе аппаратында, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең

съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу, Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына (Татарстан Республикасы Премьер-министрына) алдан хәбәр итеп, катнашудан тыш) катнашу.
в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында Җирлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;
г) җирлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә җирлекнең идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә, гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) булган оешманың идарә итү органнарында һәм ревизия комиссиясендә җирлек мәнфәгатьләрен бушлай бирү;
д) федераль законнарда каралган башка очраклар;
3) Укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнү. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;
4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче аларның структур бүлекчәләре составына керергә.

5) 38 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Җирлек башлыгы елына бер тапкырдан да ким булмаган үз эшчәнлеге нәтиҗәләре, Җирлекнең башкарма комитеты һәм аның карамагындагы башка җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәләре, шул исәптән Җирлек Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү турында җирлек Советы алдында хисап тота».

6) 43 статьяның 2 пунктындагы 7 абзацын төшереп калдырырга.

7) 43 статьяның 3 пунктындагы 3 абзацында «шул исәптән сатып алу юлы белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

8) 43 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«- Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә, үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, үз белдеге белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкция объектларының, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карарлар кабул итә.».

9) 43 статьяның 6 пунктындагы 4 абзацында «элемтәләр» сүзен төшереп калдырырга.

10) 43 статьяның 7 пунктындагы 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: « каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнаша».

11) 43 статьяның 7 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «- Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслый, аларның үтәлешен контрольдә тота, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлекне төзекләндерүне оештыра».

12) 43 статьяның 3 пунктындагы 1,3,4 пунктчаларында «Россия Федерациясе субъектлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы»сүзләренә алмаштырырга.